ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хисабы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хисабын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән берлектә фәнни-техник үсеш чараларын гамәлгә ашыруны, инвестиция һәм структура сәясәте, социаль-икътисадый программалар эшләү, җитештерүгә өр-яңа техника һәм технологияләр кертү өлкәсендә фәнни эшчәнлек субъектларының хезмәттәшлеген тәэмин итүне дәвам итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Эшчәнлекнең төп устав төрләре, Татарстан Республикасында Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында фәнни-тикшеренү эшчәнлеген дәвам итүне.

3.2. Фәнни-техник (технологик) проектларга, шул исәптән технологик лидерлыкның өстенлекле юнәлешләре буенча, грант ярдәме күрсәтүне (грант конкурсларын үткәрүне) дәвам итүне.

3.3. Россия халыклары бердәмлеге елы һәм Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы кысаларында тарихи хәтерне саклауга, татарстанлыларның Ватанны яклауга керткән өлешен һәм Татарстанның күренекле фән һәм мәдәният эшлеклеләре мирасын популярлаштыруга, рухи-әхлакый кыйммәтләрне, милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның туган телләрен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән мәгълүмат продуктларын әзерләү буенча эшчәнлекне дәвам итүне.

3.4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә түбәндәгеләр буенча эшне дәвам итүне:

Татарстан Республикасында «Алдынгы инженерлык мәктәпләре» федераль проектын гамәлгә ашыру;

талантлы яшьләрне җәлеп итү һәм аларга үз-үзләрен ачу өчен фән, технологияләр һәм инновацияләр өлкәсендә шартлар тудыру.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына фән өлкәсендә законнарны гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 17 марты
№ 586-VII ДС